| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Татар Кандызы авылы

2019 ел, 18 март №103

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 мартындагы 57 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларын раслау турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә 29.12.2004 № 190-ФЗ,Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 мартындагы 57 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Торак пунктлар чикләрендә билгеләнелә торган территориаль зоналар составына авыл хуҗалыгы куллану зоналары (шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләре зоналары), шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар белән шөгыльләнүче һәм авыл хуҗалыгын алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны үстерү өчен билгеләнгән зоналар да кертелә ала.»;

2.2.2. пунктындагы2нче таблицадан соңторган абзацнытүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Торак зоналарда аерым төзелгән яисә төзелгән социаль һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, сәламәтлек саклау объектлары, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми һәм урта гомуми белем бирү объектлары, дини биналар, автомобиль транспорты стоянкалары, гаражлар, гражданнар яшәүгә бәйле һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясамый торган объектлар урнаштыру рөхсәт ителә. Торак зоналар составына шулай ук бакчачылык алып бару өчен билгеләнгән территорияләр дә кертелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Татар Кандызы авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе М.Ш.Насыйбуллин